| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**03.03.2020** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 391** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» программасын гамәлгә ашыру кысаларында, авыл территорияләрендә яшәүче һәм эшләүче, яисә авыл территорияләренә даими яшәү урынына күчәргә һәм анда эшләргә теләк белдергән гражданнарның торак шартларын яхшырту мәсьәләсе буенча җәмәгать торак комиссиясе составы турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» программасын гамәлгә ашыру кысаларында, авыл территорияләрендә яшәүче һәм эшләүче, яисә авыл территорияләренә даими яшәү урынына күчәргә һәм анда эшләргә теләк белдергән гражданнарның торак шартларын яхшыртуның һәркем файдалана алырлык булуын арттыру максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» программасын гамәлгә ашыру кысаларында, авыл территорияләрендә яшәүче һәм эшләүче, яисә авыл территорияләренә даими яшәү урынына күчәргә һәм анда эшләргә теләк белдергән гражданнарның торак шартларын яхшыртуның һәркем файдалана алырлык булуын арттыру мәсьәләсе буенча гражданнарны исәпкә алу буенча җәмәгать торак комиссиясе составын, ТР ЗМР БК ның 2014 елның 29 августындагы 1747 номерлы карарын яңа редакциядә расларга. (1 нче кушымта).

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» программасын гамәлгә ашыру кысаларында, авыл территорияләрендә яшәүче һәм эшләүче, яисә авыл

территорияләренә даими яшәү урынына күчәргә һәм анда эшләргә теләк белдергән гражданнарның торак шартларын яхшырту мәсьәләсе буенча җәмәгать торак комиссиясе турындагы Нигезләмәне расларга (2 нче кушымта).

3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы «Авыл хуҗалыгын үстерү, авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасының «Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» ярдәмче программасы кысаларында, авыл җирендә яшәүче гражданнарның, шул исәптән яшь гаиләләрнең һәм яшь белгечләрнең торак шартларын яхшырту өчен гаиләләрне исәпкә алу буенча җәмәгать торак комиссиясе составы өлеше Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 18 декабрендәге 2791 номерлы карары үз көчен югалтты.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты житәкче урынбасары А.З. Нурмөхәммәтовка йөкләргә.

Җитәкченең беренче урынбасары А.В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 03 мартындагы
391 номерлы карарына карата
1 нче кушымта

**«Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» программасын гамәлгә ашыру кысаларында, авыл территорияләрендә яшәүче һәм эшләүче, яисә авыл территорияләренә даими яшәү урынына күчәргә һәм анда эшләргә теләк белдергән гражданнарның торак шартларын яхшыртуның һәркем файдалана алырлык булуын арттыру мәсьәләсе буенча җәмәгать торак комиссиясе составы**

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Нурмөхәмәтов Әмир Җәмил улы | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы, комиссия рәисе |
| 2. | Зиннуров Рамил Наил улы | «Зеленодольск муниципаль районының техник күзәтү хезмәте» МУП директоры, комиссия рәисе урынбасары |
| 3. | Демина Мария Григорьевна | «Зеленодольск муниципаль районының техник күзәтчелек хезмәте» МУП авылда АПК программасын гамәлгә ашыру бүлеге белгече, комиссия секретаре |
| **Комиссия әгъзалары:** | | |
| 4. | Зиганшин Таһир Галимҗан улы | Зеленодольск муниципаль районында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы |
| 5 | Гыйбадуллин Илһам Рашит улы | Россия Эчке эшләр министрлыгының Зеленодольск районы буенча бүлегенең икътисадый иминлек һәм коррупциягә каршы тору бүлеге өлкән оперуполномоченные, полиция майоры |
| 6. | Хазиев Рәсим Зөфәр улы | Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге начальнигы (килешү буенча) |
| 7. | Минһаҗев Нияз Наил улы | «Зеленодольск муниципаль районының Торак сәясәте департаменты» МКУ җитәкчесе (килешү буенча) |
| 8. | Таһиров Наил Нәҗип улы | «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» КБОның Зеленодольск муниципаль районындагы вәкиле (килешү буенча) |
| 9. | Копвиллем Наилә Нургаяз кызы | Зеленодольск муниципаль районында мәгариф һәм фән хезмәткәрләренең территориаль профсоюз оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| 10. | Гаврилова Ригина Анатольевна | РФ, ТР сәламәтлек саклау хезмәткәрләре профсоюзының Зеленодольск район оешмасы рәисе (килешү буенча) |

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 03 мартындагы
391 номерлы карарына карата

**«Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» программасын гамәлгә ашыру кысаларында, авыл территорияләрендә яшәүче һәм эшләүче гражданнарның йә даими яшәү урынына авыл территорияләренә күчәргә һәм шунда эшләргә теләк белдергән гражданнарның торак шартларын яхшыртуның һәркем файдалана алырлык булуын арттыру мәсьәләсе мәсьәләсе буенча җәмәгать торак комиссиясе турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмә

1.1. Җәмәгать торак комиссиясе Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары (алга таба – Башкарма комитет) белән төзелә, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарны дөрес исәпкә алуны тәэмин итү функцияләрен башкара.

1.2. Җәмәгать торак комиссиясе составы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән раслана.

1.3. Җәмәгать торак комиссиясе үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив-хокукый актлары, шулай ук әлеге Нигезләмә белән җитәкчелек итә.

2. Җәмәгать торак комиссиясенең төп бурычлары

2.1 Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы карары (алга таба - Программа) белән расланган «Авыл территорияләрен комплексы үстерү» программасын гамәлгә ашыру кысаларында, гражданнарның торак шартларын яхшыртуга гаризаларын карау.

2.2 Программаны гамәлгә ашыру кысаларында, кирәкле документларның гаризага кушып бирелгән тулылыгын һәм дөреслеген тикшерү.

2.3 Авыл территорияләрендә яшәүче, яисә авыл территорияләренә даими яшәү урынына күчәргә һәм анда эшләргә теләк белдергән гражданнарга торак төзү (сатып алу) өчен социаль түләүләр бирү турындагы нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда торак төзү/сатып алу өчен социаль түләүләр (субсидияләр) бирү, гражданнарга социаль түләүләр (субсидияләр) бирүнең туры килүе/туры килмәве турында карар кабул итү.

2.4 Чираттагы финанс елның җыелма исемлекләренә кертелгән авыл территорияләрендә яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшыртуга хисап эшләрен формалаштыру һәм алып баруның дөреслеген Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә тикшереп тору.

2.5 Чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан бирелгән 1 кв.м. норматив бәясе

булганда, социаль түләүләр (субсидияләр) алучыларның җыелма исемлеген килештерү.

2.6 Аерым, ординар булмаган очракларда гражданнарга торак төзелешенә/сатып алуга социаль түләүләр бирү турында нигезләмәдә билгеләнгән шартлардан тайпылып, социаль түләүләр (субсидияләр) биргәндә гражданнарның финанс елының җыелма исемлекләренә кертү/кермәү турында карар кабул итү.

2.7 Комиссия утырышына кирәкле мәгълүматны алу һәм төп мәсьәләләрне караганда аңлатмалар алу өчен вазыйфаи затларны, белгечләрне чакырырга.

## 3. Җәмәгать торак комиссиясе составы

3.1. Җәмәгать торак комиссиясе составына Башкарма комитет, профсоюз һәм башка җәмәгать оешмалар (алга таба комиссия әгъзалары) вәкилләре керә.

3.2. Җәмәгать торак комиссиясе түбәндәге әгъзалардан торырга тиеш:

- җәмәгать торак комиссиясе рәисе;
- җәмәгать торак комиссиясе рәисе урынбасары;
-секретарь;
- комиссия әгъзалары.

3.3. Җәмәгать торак комиссиясен рәис җитәкли. Җәмәгать торак комиссиясе рәисе булмаганда, аның бурычлары комиссия рәисе урынбасарына йөкләнә.

3.4. Кворум өчен җәмәгать торак комиссиясе составы так сан, әмма биштән кимрәк булмаган саныннан торырга тиеш.

## 4. Җәмәгать торак комиссиясе эшчәнлеген оештыру

4.1. Җәмәгать торак комиссиясе рәисе комиссияне җитәкли һәм аның эшен оештыра.

4.2. Җәмәгать торак комиссиясе утырышлары сораулар кергән очракта үткәрелә. Утырышлар, әгәр анда җәмәгать торак комиссиясе әгъзаларының 50% тан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

4.3. Секретарь чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан бирелгән 1 кв.метр норматив бәясе булганда, социаль түләүләр (субсидияләр) алучыларның җыелма исемлегенә кертү турындагы мәсьәләне карау өчен кирәкле документларны әзерли.

4.4. Җәмәгать торак комиссиясе утырышында тикшерелә торган Программа шартларына туры килү/килмәү турындагы сораулар җәмәгать торак комиссиясе утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

4.5. Җәмәгать торак комиссиясе карары, утырышта катнашучыларның күпчелеге аның өчен тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

## 5. Җәмәгать торак комиссиясенең җаваплылыгы

5.1 Җәмәгать торак комиссиясе әгъзалары җәмәгать торак комиссиясе утырышында кабул ителгән карарлар өчен программа шартларына туры килү/килмәү турында уртак җаваплылык тоталар